ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МЕНЗЕЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНЗӘЛӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

21. 06. 2016 г.Мензелинск № 647

Суд тарафыннан хокукка сәләтсез яисә хокукка сәләте чикләнгән дип танылган балигъ булган затларга карата опека һәм попечительлек өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибенә үзгәрешләр кертү турында» 2015 елның 17 апрелендәге 259 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 елның 2 декабрендәге 880 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 елның 17 апрелендәге 259 номерлы карары нигезендә;

КАРАР ЧЫГАРАМ:

1. Расларга:

1.1. Балалар бакчасында тәрбияләнүчеләрне стационар формада социаль хезмәтләр күрсәтүче социаль учреждениеләргә җибәрү турында карарлар бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты (1 нче кушымта).

1.2. Суд тәртибендә хокукка сәләтсез яисә хокукка сәләте чикләнгән дип танылган балигъ булган зат өстеннән опекун яисә попечитель билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты (2 нче кушымта).

1.3. Тәрбиягә алынган бала мәнфәгатьләрендә гомерлек рента шартнамәсе төзүгә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты (3 нче кушымта).

1.4. Балигъ яшьтәге хокукка сәләтсез зат мәнфәгатьләрендә торакны хосусыйлаштыруга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең

административ регламенты (4 нче кушымта).

1.5. Опекунга тәрбиягә алынган кешенең торак тапшыруына рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты (5 нче кушымта).

1.6. Тәрбияләнүчеләрнең мөлкәте белән алыш-бирешләр кылуга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты (6 нчы кушымта).

1.7. Яшәү урыны үзгәрүгә бәйле рәвештә опекунга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты (7 нче кушымта).

1.8. Опекун яки попечительгә тәрбиягә алынучының нәсел хокукларына керү өчен рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты (8 нче кушымта).

1.9. Опекунга яисә попечительгә тәрбиягә алучының саклык счетыннан файдалануга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты (9 нчы кушымта).

1.10. Суд тәртибендә социаль учреждениедә стационар хезмәт күрсәтүдә булган хокукка сәләтсез дип танылган балигъ булган затны Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче гражданнар гаиләләренә вакытлыча тапшыру турында дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты (10 нчы кушымта).

2. «Опека һәм попечительлек өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең 2013 елның 09 апрелендәге 334 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Минзәлә муниципаль районы Башкарма комитетының гомуми бүлегенең баш белгече Л.С. Нәбиуллина өч эш көне эчендә әлеге Карарны Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыруны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Минзәлә муниципаль районы Башкарма комитетының эшләр идарәчесе Т.М. Урошникова га йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Минзәлә муниципаль районы
Башкарма комитет җитәкчесе И.Т. Шагалиев